## *Хөрмәтле Минзифа Гыйльми кызы!*

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм шәхсән үз исемемнән Сафин Фәйзрахман Әхмәтҗан улы исемендәге Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбенә нигез салынуга 100 ел тулу уңаеннан ихлас күңелдән котлыйм!*

*«Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк», - ди бөек халкыбыз. Уку йортының данлы тарихына олы ихтирам белән караган, матур традицияләрен буыннардан буыннарга олы хөрмәт белән тапшырып барган, республикада мәктәпнең абруен арттыруга армый-талмый көч куйган өчен мөгаллимнәргә, тырыш укучыларга олы рәхмәтемне җиткерәм.*

*Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе милләтебезгә рухи яктан бай һәм зыялы шәхесләр тәрбияләүгә, яшь буынга тирән белем бирү һәм татар мәгарифен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә, туган телебезне, мәдәниятебезне, халкыбызның милли гореф-гадәтләрен укучыларга түкми-чәчми тапшырырга тырыша.*

*Шәле урта гомуми белем бирү мәктәбе республикада үзенең укучылары белән данлыклы. Бүген алар, кайда гына гомер кичерсәләр дә, яшәешләре, кылган гамәлләре, ирешкән уңышлары белән һәркемгә үрнәк.*

*Һәммәгезгә дә сәламәтлек, иминлек, намуслы хезмәтегездә уңышлар юлдаш булсын, иҗади эзләнүләр һәм табышлар, акыллы һәм тырыш укучылар телим!*

*Татарстан Республикасы*
*Премьер-министры урынбасары –*
*Татарстан Республикасы*
*мәгариф һәм фән министры* *Э.Н. Фәттахов*